ГЛАВА БУРНАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево, 422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ БОРНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы, 422579

Тел.: (84379) 36-2-45, факс: (84379) 36-2-45.

2022 елның 30 октябре                                                                                    № 3

КАРАР
Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Юматово авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Юматово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме? - сатучы хисабына товарны тиешле пунктка илтеп җиткереп, Юматово авылына юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу, дигән сорау буенча 2022 елның 30 октябрендә гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 19 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 11 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында 11 катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Юматово авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип танылды.

2. «2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Юматово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, авыл җирлеге Башкарма комитетының карары белән билгеләнгән ташламалы категориядәге гражданнардан тыш, һәр балигъ булган кешедән Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Юматово авылында 1500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме? - сатучы хисабына товарны тиешле пунктка илтеп җиткереп, Юматово авылына юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу, дигән сорау буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлегенең Юматово авылында халык җыены нәтиҗәләрен Борнаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: С. В. Бурукин